ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
**27.03.2020**

Зеленодольск
шәһәре

**КАРАР**
**№613**

Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының «Зеленодольск шәһәре территориясен санитар чистарту һәм төзекләндерү буенча гомумшәһәр чараларын уздыру турында» 2020 елның 23 мартындагы 579 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Халыкның санитар-эпидемиологик иминлеген тәэмин итү һәм яңа коронавир инфекциясе таралуны булдырмау максатларында, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының «Зеленодольск шәһәре территориясен санитар чистарту һәм төзекләндерү буенча гомумшәһәр чараларын уздыру турында» 2020 елның 23 мартындагы 579 номерлы карарының 1 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«18.04.2020 нан 17.06.2020 на кадәр Зеленодольск шәһәре территориясен санитар чистарту һәм төзекләндерү буенча икеайлык игълан итәргә (алга таба - икеайлык)».

2. Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының «Зеленодольск шәһәре территориясен санитар чистарту һәм төзекләндерү буенча гомумшәһәр чараларын уздыру турында» 2020 елның 23 мартындагы 579 номерлы карарының 2 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Шәһәр территориясен санитар чистарту буенча чәршәмбе өмәләре 22.04.2020, 29.04.2020, 06.05.2020, 13.05.2020, 20.05.2020, 27.05.2020, 03.06.2020, 10.06.2020, 17.06.2020 һәм шимбә өмәләре 18.04.2020, 25.04.2020, 16.05.2020, 23.05.2020, 30.05.2020, 06.06.2020 үткәрергә».

3. Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының «Зеленодольск шәһәре территориясен санитар чистарту һәм төзекләндерү буенча гомумшәһәр чараларын уздыру турында» 2020 елның 23 мартындагы 579 номерлы карарының 4 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Идарәче компанияләргә, күчемсез милек милекчеләре ширкәтләренә, торак милекчеләре ширкәтләренә 18.04.2020, 25.04.2020, 16.05.2020, 23.05.2020, 30.05.2020, 06.06.2020 халык катнашында йорт яны территорияләрен җыештыру буенча өмәләр оештырырга тәкъдим итәргә ».

4. Зеленодольск муниципаль районы Советы аппаратының җәмәгатьчелек, массакүләм мәгълүмат чаралары белән элемтә бүлеге начальнигына әлеге карарны массакүләм мәгълүмат чараларында бастырып чыгарырга, Интернет челтәрендәге хокукый мәгълүматның рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Зеленодольск муниципаль районының мәгълүмат сайтында http://zelenodolsk.tatarstan.ru) урнаштырырга тәкъдим итәргә.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Зеленодольск муниципаль районы
Башкарма комитеты
Җитәкчесенең беренче урынбасары А.В. Старостин